СОВЕТ ТАНАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЕЛАБУЖСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АЛАБУГА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ТАНАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

№ 195 26.12.2019

Алабуга муниципаль районы Танай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы «Танай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 14 декабрендәге 155 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 2 августындагы 283-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезендә һәм Алабуга шәһәр прокуратурасы протестын караганнан соң, Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының Танай авыл җирлеге Советы

КАБУЛ ИТТЕ:

1. Алабуга муниципаль районы Танай авыл җирлеге Советының «Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районы «Танай авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә гавами тыңлауларны (җәмәгать фикер алышуларын) оештыру һәм уздыру тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2018 елның 14 декабрендәге 155 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 4 бүлегендәге 11 статьясының 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проекты буенча гавами тыңлауларының дәвамлылыгы әлеге проект басылып чыккан көннән соң кимендә бер ай һәм өч айдан артык булмаган вакытны тәшкил итә. »

2. Әлеге карар рәсми рәвештә бастырып чыгарылырга тиеш.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Рәис П.А. Макаров